| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КУГУНУРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ КУНЫР АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|

---

**ПОСТАНОВЛЕНИE** «26» март 2019 г.

**КАРАР** № 7

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы №196 «Татарстан Республикасында Күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» карары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. 2019 елның 1 февраленнән Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 5946,47 сум итеп, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Куныр авыл җирлеге башкарма комитеты
Җитәкчесе урынбасары И.Н.Назипова